

Ботен ил буенча vткән айда 146 хайваннын котыру очрагы теркәлгән. Котырган толкеләр ешрак - 63 очрак. Этләр арасында котыру авыруынын 38 очрагы ачыкланган, мәчеләр арасында - 24 очрак. Шулай ук енотсыман этләр, эре һәм вак могезле терлекләр, бурсык һәм хорек котырган авыруы йоктырганнар. Ин кvп очраклар Чиләбе, Белгород, Мәскәv, Рязань, Самара, Воронеж, Пенза олкәләрендә, шулай ук Удмурт Республикасында ачыкланган. Регион халкын толкеләр популя-циясенен шактый артуы сагайта. Эпизоотологлар толкеләргә обстрел булмау да мона сәбәп, ди. Йорт хайваннарына котыру авыруы йоктырган толкеләр һожvм итсә, кvпкә куркынычрак. Барлыгы регионыбыз буенча 9 терлекнен котыру авыруы йоктырган очрагы теркәгән. Мордовиянен кайбер районнарында карантин да ачканнар иде, дип хәбәр итә Россельхознадзор һәм ветеринария хезмәт ияләре. Әйтеп киткән хезмәткәрләр регионыбызда котыру авыруын булдырмау буенча чаралар да оештырганнар. Мәсәлән, «Ельниково РСББЖ» ветеринария хезмәте унай эпизоотик хәлгә зур олеш кертә, шул исәптән, терлекләрнен котыруы буенча да. Район ветеринария белгечләре бу vлем куркынычы булган вирус авыруын профилактикалау буенча бик зур эш башкардылар. Котыру авыруыннан 8 мен баш могезле эре терлеккә, 1300 баш терлеккә прививка ясаганнар. Кыргый хайваннар очен вируска каршы вакцинаны vз эченә алган 2 мен приманка жәелгән. Эш озлексез алып барыла, чонки кvрше Краснослобод районында йорт хайваннарында котыру очрагы теркәлгән.

- Без даими рәвештә гражданнарга котыру авыруыннан саклану юлларын исләренә тошерәбез. Бу куркыныч афәтне ерып чыгу очен момкин булганнын барысын да эшлибез, ә кайвакыт момкин булмаганны да эшләргә туры килә. Район халкын кыргый табигать белән аралашуда саграк булырга кисәтәбез, - ди врач-эпизоотолог Иван Васильевич Бушукин. - Бер салкынлык мисалын китерәм. Краснослободск зооветтехникумы студенты, vз куллары белән тотарга теләп, норка-чәшке аулый. Чәшке аучыны тешләгән. Ул котыру авыруын йоктыра, чонки тиздән яшь кешенен характерлы билгеләре барлыкка килә: паникага тошv формасында судан курку, баш мие шешv һәм ... яшь тормыш озелә. Бу зур фажига, аны булдырмый калырга момкин иде.

Башта Ельник ветеринария хезмәте периферияда котыру авыруыннан вакцинация эшләде, аннары район vзәгендә яшәvчеләр очен йорт хайваннарынын котыру авыруыннан вакцинацияләv буенча зур кvләмле эш башкардылар. Чара нәтижәсендә Ельник бистәсендә генә дә 169 эт һәм 228 песигә прививка ясалган.

«Вакцинацияне без ял коннәрендә уздырдык, бу хакта район газетасында хәбәр иттек, - ди районнын баш ветеринария табибы вазыйфаларын башкаручы А.И.Лазарев. - Шуна кvрә йорт хайваннары хужаларынын кvбесе ветеринария табибы килvен котте. Әмма, кемдер ойдә юк, кемдер урамда йоргәннән сон хайванны тота алмаганнар да булды. Шуна да прививкалар ясатмаган йорт хайваннарын безгә участокка алып килделәр. Халыкнын котыру авыруы нинди куркыныч тудыруын анлавы куанычлы. Остәвенә, хайваннарнын котыру авыруыннан иммунитетын саклау чарасы бушлай уздырыла. Бу - дәvләт эше, ул хайваннар иминлегенә генә тvгел, ә кеше иминлегенә дә кагыла». Зооветеринария белгечләре авыру толкеләрнен йорт хайваннарына һожvм итv очраклары турында ветслужбага хәбәр итv, кешегә һожvм иткән вакытта кичекмәстән медицина ярдәме сорап морәжәгать итv кирәклеге турында тагын бер кат искәртә.

Наилә Насырова